

# *Шигырьләре – күңел дөньясы*

**Зөлфия Җиһан табигатьнең иң гүзәл бер почмагында – Башкортстанның Туймазы районы Карат авылында туып-үскән. Балачагы ямьле Ык буенда үткән: суында коенган, әрәмәдән җиләк, урманыннан чикләвек җыйган. Беренче шигырьләре аның шул елларда ук туган, тик, кызганычка каршы, иҗат җимешләренең берсен дә сакламаган. Яр Чаллының «Энергетик» мәдәният сараенда эшләгән чорда ул шәһәрнең үзәк китапханәсенә йөри башлый.**
**Шул вакытта аның шигырьләре дә әкренләп туплана. 2003 елда җырлар язуга да сәләте ачыла.**
**Зөлфия ханым иҗат эшен бүген дә дәвам итә, Чаллының «Ләйсән» иҗат берләшмәсенә йөри.**

## Кар бөртеге

Өр яңа бер кар бөртеге җиргә төште,
Әй, кычкырып җырлады ул, әй, шатланды.
Шаян җилдән күтәрелеп кабат очты,
Үзе кебек очканнарны үпте, кочты.

Бөтерелеп, уйнап-көлеп оча торгач,
Дуслары белән дә шаярып арыгач,
Бераз гына ял итәсе аның килде,
Иренемә минем кунды һәм... эреде...

«Кар бөртеге, кар бөртеге, ник эредең?
Шундый матур итеп биеп җырлый идең.
Җылы сине эреткәнне ник белмәдең,
Нигә инде иренемә килеп кундың?»

Эрегән кар бөртекчеге телгә килде:
«Һич кенә дә кайгырма син, кеше, – диде –
Кар булсам да, пар булсам да, су булсам да,
Боз булсам да мин һаман да тере! – диде. –

Ялап ал әле син мине иренеңнән,
Җәлләп торма, тәмләп-тәмләп йотып җибәр.
Моңсу уйларыңны кусаң күңелеңнән,
Миндәге шатлык һәм сафлык сиңа күчәр!!!»

## Хыялый минутларымда

Йолдызлар кабынган чакта
Тоярга телим үземне
Тик синең җылы кочакта,
Ишет, сөямен тик сине.

Болытларга кунып йөзәм
Мәхәббәт дәрьяларында.
Мин риза киярга йөгән
Сөелү дөньяларында.

Тылсымлы әкият булып,
Яратудан канатланып,
Шатлык-сөенечкә тулып,
Яшисе иде назланып.

Синең бәхетле икәнне
Күзләреңнән күреп беләм.
Мине өзелеп сөйгәнеңне
Тоям... Мин дә сине сөям!

***

Башым аска иеп йөргән көннәремдә,
Кая барып бәрелергә белмәгәндә,
Маңгаена шешләр җыйган кешеләрдән
Аңлау тойдым ярдәм эзләгәндә.

Ачу тотмыйм кабәхәт, явыз җаннарга,
Кеше каны эчеп яши торганнарга...
Адым саен миңа аяк чалганнарга,
Шул юл белән үз бәхетен тапканнарга...

Рәхмәтлемен ярдәм кулы сузганнарга,
Авыр чакта кырыемда булганнарга...
Рәхмәтлемен нахак сүздән сыгылганда
Мине яклап, терәк булып торганнарга...

Гуфу итәм, гафу итәм, гафу итәм,
Гафу итәм, үткәннәрне гафу итәм.
Гафу итәм, гафу итәм, гафу итәм,
Гафу итеп яктылыкка таба китәм!!!

## Мәсәл

Сандугачка иярергә
Тырыша бер чыпчык.
Сандугач булып сайрарга
Маташа, кылтайчык.
Ник аңламыйлар чыпчыклар
Матур сайрар өчен
Һич тырышмый сандугачлар
Салып соңгы көчен...
Чыпчыклар, яратылгансыз
Сез бу дөньяга,
Чыркылдарга, ә сайравын
Сандугач сайрасын...

***

Күктән йолдыз атылганда
Теләк теләдем.
«Сөйгәнемне үземнеке
Итәрмен», – дидем.
Нигә соң мин шул чагында,
Нигә белмәдем?..
Сөйгәнем башка берәүне
Бәлки сөярен?..

*******

Ык буенда, ямьле җирдә
Урнашкансың, авылым.
Кайларда гына йөрсәм дә,
Сине гел сагынырмын!

Татлы сулы чишмәләрең,
Җиләкләрдәй кызларың,
Баһадирдай егетләрең
Белән бай син, Каратым!

## Еллар аша

Еллар аша, артта калган юллар аша
Мин күрәмен хыялый бала чагымны.
Күңелемдә ургылып хисләрем таша,
Очратсам шунда тәүге сөйгән ярымны...

Мәхәббәттән янып-көйгән күңелемне
Ача алмадым шул сиңа, кичер мине.
Көлләргә әйләнеп очкан хисләремне
Кабат җыеп булмас, җаным...
Соң шул инде...

Янган, беткән, таралган да онытылган,
Димәк, шулай булырга ул тиеш булган...
Су сибәргә кайчандыр соңга калынган,
Язмышларны үзгәртергә сәбәп кылган.

*******

Көзнең алтын яфраклары,
Язның назлы җилләре,
Кышның тылсымлы карлары,
Җәйнең сихри төннәре,
Ямь өстәми синнән башка,
Керми күңелгә нуры...

***

Һәркем үз язмышын яши бу дөньяда,
Һәр язмышның үз төсе: ак, яшел, кара...
Нинди төстә булса да, шул бер үк ара –
Беренче нокта соңгыга алып бара...

Күпне күрдем: алдандым,
кыйналдым, баттым...
Калкып чыктым, күтәрелдем, чәчәк аттым!..
Ышандым да буйсындым, кабат ялгыштым,
Шулай да йөземне сакларга тырыштым...

Бүре булып «улаган» чакларым булды...
Кайвакыт теләгем яшәргә калмады...
Күңелемдәге гөлләрем кипте, сулды,
Гөлбакчам, гүя, файдасыз чүпкә тулды.

Беркем гөнаһсыз түгел,
әлбәттә, мин дә...
Тайпылганнарны мин күрдем гомеремдә.
Кемдер теләп, кем мәҗбүри эшләсә дә,
Шул ук хаталарны эшли нәтиҗәдә...

## Яратам

Яратам мин якты көнне,
Кызарып таң атканын.
Таң атканда сандугачлар
Куанып сайрашканын.

Яратам мин серле төнне,
Йолдызлар атылганын.
Ай нурында сөйгәнемнең
Чәчләремнән сыйпавын.

Яратам мин язлар җиткәч
Шомырт чәчәк атканын.
Тирә-юньгә, бар җиһанга
Хуш исләр таратканын.

Яратам язның беренче
Умырзая чәчәген.
Әрәмәдә кузгалаклар,
Кукылар өлгергәнен.

Яратам мин җәйләр җиткәч
Болыннарда йөрергә.
Җиләкләр тулышып пешкәч
Сайлап-сайлап өзәргә.

Яратам мин алтын көзне,
Миләшләр җитлеккәнен.
Бакчаларда чүп яндырган
Сихри төтен исләрен.

Яратам мин ак кышларны,
Ябалак кар яуганын.
Чатнап торган суыкларда
Җырлап кар шыгырдавын.

Яратам Ык буйларымны,
Тәнбоеклы ярларын.
Сиңа сөйләдем серләрем,
Сакла, белмәсен беркем...

Яратам, туган авылым,
Матур табигатеңне.
Яратам туганнарымны,
Мәрхәмәтле халкымны.

Яратам туган йортымны,
Чирәмле ишегалдын.
Ялантәпи йөгереп йөргән
Сабый чак синдә калды.

Яратам мин яратырга,
Сөелеп назланырга.
Яраттырып яратырга,
Яратып яратырга!!!

